АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** 15.07.2025

**КАРАР** 328

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 06.12.2022 ел, № 148 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга, Алексеевск муниципаль районы Уставына туры китереп

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2022 елның 6 декабрендәге 148 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары, яр буйлары), гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләрен урнаштыру территорияләре);»;

1.2. 3.19 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль чарасының акты рәсмиләштерелгәннән соң тикшерелгән затка мәҗбүри таләпләрдә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең акыллы срокларын күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Сафина Г.Т.).

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С. А. Демидов**